ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7, № 12 (III өлеш); 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.6 статьяның 1 өлешендә «төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләрен,» сүзләреннән соң «әлеге Кодексның 3.17 статьясында каралган очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

2) 3 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 3.17 статья өстәргә:
«3.17 статья. **Транспорт чараларын яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннар йөртү өчен мәйданчыкларда, шулай ук йорт янындагы территориядә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында урнаштыру**

Транспорт чараларын торак пунктлар чикләрендәге яшелләндерелгән территорияләрдә (газоннарны, чәчәк түтәлләрен һәм үлән үсемлекләр белән

капланган башка территорияләрне кертеп), балалар һәм спорт мәйданчыкларында, шулай ук йорт янындагы территориядә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында урнаштырган өчен –

гражданнарга – ике меңнән алып өч мең биш йөз сумга кадәр; вазыйфаи затларга – биш меңнән алып егерме мең сумга кадәр; юридик затларга илле меңнән алып йөз мең сумга кадәр административ штраф салына.

Искәрмә. Әлеге статьяның нигезләмәләре юридик затларның һәм гражданнарның хокукка каршы гамәлләрне булдырмауга, аварияләрне, табигать бәла-казаларын, башка гадәттән тыш хәлләрне булдырмауга һәм аларның зыяннарын бетерүгә, янгыннарны сүндерүгә, гражданнарның иминлеген тәэмин итүгә яисә халыкның яшәешен тәэмин итү объектларының эшләвенә бәйле кичектергесез эшләрне башкаруга, оборона чараларын (шул исәптән гражданнар оборонасы һәм мобилизация буенча чараларны) үтәүгә, дәүләтнең оборона сәләтен һәм иминлеген тәэмин итүгә, җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген саклауга, гражданнарны коткаруга, аларның тормышына яисә сәламәтлегенә куркыныч янауны бетерүгә юнәлдерелгән гамәлләренә таралмый.»;

3) 7.4 статьяда «3.16,» саннарыннан соң «3.17,» саннарын өстәргә;

4) 8.1 статьяның 14 өлешендә «3.16,» саннарыннан соң «3.17,» саннарын өстәргә;

5) 8.3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«8.3 статья. **Беркетмә төземичә административ җәза билгеләү**

Әлеге Кодексның 3.16, 3.17 статьяларында каралган административ хокук бозу турындагы эшләр, бу административ хокук бозулар фотога һәм киногa төшерү, видеога язу функцияләре булган автоматик режимда эшләүче махсус техник чаралар яисә фотога һәм киногa төшерү, видеога язу чаралары белән фиксацияләнгән очракта, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.6 статьясындагы 3 өлеше нигезендә беркетмә төзелмичә карала.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 7; 2015, № 3, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш), «3.14 – 3.16» саннарын «3.14 – 3.17» саннарына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 19 март
№ 14-ТРЗ